ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.02.2025 г.Лениногорск № 115

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 505 номерлы карары белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 487-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 13 февралендәге 505 номерлы карары белән расланган Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.19.1 пунктның «в» һәм «г» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, моңа Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объектының мәйданы, линия объектының озынлыгы үзгәрү очраклары керми;»;

«г) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты параметрларының проект документациясенә туры килмәве, моңа Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданы, линия объекты озынлыгы үзгәрү очраклары керми;».

2. Әлеге карар 2025 елның 01 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н. Гирфанов

Галимова Л.М.
5-44-72